| ГЛАВА<br>ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЛӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
2025 ел, 11 нче ноябрь

**КАРАР**
№ 6

Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегендә
2026 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Дружба авылында халык җыенын билгеләү турында

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының “Ләке авыл җирлеге” муниципаль берәмлек башлыгы КАРАР чыгарды:

1. 2025 елның 21ноябрендә 13.00 сәгатьтә Сарман муниципаль районы, Дружба авылы, Урман ур., 15 адресы буенча урнашкан 15-нче номерлы йорт янында 2026 елда Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегенең Дружба авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Дружба авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән гражданнар; көндезге формада белем алучы студентлар; ашыгыч хәрби хезмәт узучы гражданнар, контракт буенча хәрби хезмәт узучылар, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә килешәсезме:

1) Дружба торак пунктында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, зиратка кадәр юлларга вак таш түшәү (махсус техниканы арендалау, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, вак таш ташу,юлга салу һәм тарату);

2) Дружба торак пунктында урамнарның тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы карап тору (шартнамә буенча лампа, энергияне сак тоту яктырткычлары, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

"ӘЙЕ "                " КАРШЫ?»

3. «Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге башлыгы карары «2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында» 2025 елның 10 ноябрендәге 3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4.Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең информацион стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

5. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы                                   Ю.Г.Антонов